Өркеш авыл җирлеге Советы
Кукмара муниципаль районы
Татарстан Республикасы

# *КАРАРЫ*

От 09 июня 2021 года №8

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль
районы Өркеш авыл җирлегенең Җирдән файдалану
һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Өркеш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Өркеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Өркеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы карары (2016 елның 16 декабрендә 32 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 9 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге 1 номерлы, 2019 елның 22 августындагы 9 номерлы Өркеш авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Өркеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә», 18.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

«18. 1. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлегенең максималь күләме – 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Глава Уркушского
сельского поселения А.Ш.Аглямова

ОГРН 1021607752870
ИНН 1623001822